Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең
Акташстанциясе гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

24 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022елның 23 ноябрендә17сәгать 00 минутта гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендәтүбәндәге "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге Акташ станциясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрүгә түләүгә ризамы?» соравы буенчагражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыененың нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 109 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 98 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 98 «РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның0«КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташыавыл җирлегенең Акташ станциясендәгражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыененың нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге Акташ станциясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару: балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, сметалар төзүгә һәм техник күзәтчелек үткәрүгә түләүгә ризамы?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Акташ станциясе контора бинасы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендәӘлмәт муниципаль районы сайтында«Интернет»мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Рус Акташы авыл җирлеге башлыгы С. А. Белоногов